ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЛМИЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

“20” ноябрь 2018 ел Калмия авылы №22

Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең 2019 елга һәм 2020-2021 еллар план чорына бюджет проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү турында

Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге халкының «2019 елга, 2020-2021 еллар план чорына Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге бюджеты проекты турында» гы карар проекты буенча фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатыннан, 06.10.2003 ел № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законга, Калмия авыл җирлеге Уставына, "Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегендә халык алдында тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында" Нигезләмәсенә таянып,

**карар итәм:**

1. 2018 елның 15 ноябрендә Калмия авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерелгән Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Советының «Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең 2019 елга һәм 2020-2021 еллар план чорына бюджеты турында» гы карары проекты буенча тыңлаулар үткәрергә.

2. Әлеге карарны 2018 елның 21 ноябреннән дә соңга калмыйча җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Билгеләргә:

3.1 халык тыңлаулары үткәрү вакыты – 28.11.2018 ел 10.00 сәгатьтә;

3.2 үткәрү вакыты – 1 көн;

3.3 үткәрү урыны – Татарстан Республикасы, Тукай районы, Калмия авылы, Молодеңная урамы, 24 йорт (Калмия авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы)

3.4 фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тәкъдим ителә ала торган адрес: ТР, Тукай районы, Калмия авылы, Молодеңная урамы, 24 йорт (эш көннәрендә – 8.00 сәгатьтән 16.20 сәгатькә кадәр)

4. Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге башкарма комитетына «2019 елга, 2020-2021 еллар план чорына Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге бюджеты турында» карар проекты буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Калмия авыл җирлеге башлыгы Р.Ә.Гарипов